ISSN 0868-4545

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

№ 09.2009



БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ CHILDREN'S MAGAZINE





Әлифба кебек ача ул
Серле дөнья капкасын
Словно Азбука ты открываешь
нам чудесный мир
You show us the wonderful
world as ABC



Сыбызгы



НӘРСӘ УЛ УНИВЕРСИАДА?

№9(234) — 2009

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

балалар журналы · детский журнал · children's magazine

Журнал 1990 елның
март аеннан бирле чыга.
Журнал основан
в 1990 году.
На татарском языке.

© «Салават күпере», 2009 ел

ЖУРНАЛГА
ЯЗЫЛУ ӨЧЕН ИҢ
ӘЙБӘТ ВАКЫТ.
ИНДЕКС - 73953

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бүлек мөхәррире
Зилә ЯЗ

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ



АНОНСИК



ӘЛЧИ-БӘЛЧИ,
ӘНИ КҮЛМӘК ҮЛЧИ... 6 нчы бит.

СОРЫ БҮРЕ НИЧЕК УЛЫЙ ? 10 нчы бит.

ПЕСИ ГАРМУН УЙНАДЫ,
КӘҖӘ ДИРИЖЕР БЕЗДӘ... 14 нче бит.

УНИВЕРСИАДАДА
СИН ДӘ КАТНАШ ! 18 нче бит.

АНОНСИК

Журналның дизайны:
Валера ФОМИН,
Алла АЙСЕНА

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 03.09.2009 ел.
Кәгазь форматы 60x90 1/8.
Гарнитура — Футурис. Офсет ысулы белән басыла. Заказ В-1234. Тираж 6906 данә.

Журналны гамәлгә куючы — «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте

Тираж сертификацияләнгән

БӘЯСЕ КИЛЕШҮ БУЕНЧА
ИНДЕКС 73953

Санны әзерләүчеләр: З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, З.Яз, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Безнең адрес: 420012, г.Казань, ул.Муштари, 14. Тел.: 236-61-98, 236-00-81, 236-61-97
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 321 номер белән 1994 елның 4 февралендә теркәлде.

«Идел-Пресс» ачык акционерлар җәмгыятендә басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.



Тышлыкта
Алла АЙСЕНА рәсеме

Белем иле көтә безне



Алсу белән Нияз мәктәпкә килде. Алар беренче сыйныфта бергә укыячаклар.

— Син укый-яза беләсеңме? — дип сорады Алсу Нияздан.

— Әйе, беләм, — дип җавап бирде Нияз. — Балалар бакчасында өйрәттеләр.

— Ә мине «Салават күпере» журналы укырга-язарга өйрәтте. Әти белән әни дә бик булышты, — диде Алсу.

— Алайса безгә «Әлифба»ны уку бик кыен булмаячак, — дип нәтиҗә ясады малай.

— Синең белән килешәм, — диде Алсу.

— Безгә укырга да укырга әле. Алга таба дәресләр күп булачак, — диде Нияз һәм өстәп куйды: — Апам да шушы мәктәптә укый. Шуңа күрә белеп әйтүем...

Укытучы апалары Нияз белән Алсуны бер партага утыртты.

Белем иленә, гыйлем дөньясына күңелле, мавыктыргыч сәяхәт әнә шулай башланды.

ДУСЛАР!

БЫЕЛ КЕМНӘР МӘКТӘП БУСАГАСЫН ТӘҮГЕ МӘРТӘБӘ АТЛАП УЗДЫ?

БЕРЕНЧЕ СЕНТЯБРЬ СЕЗДӘ НИНДИ УЙЛАР, ТӘЭСИРЛӘР КАЛДЫРДЫ?

Газиз НӘБИУЛЛИН

Мәктәбем

Бу йортта никадәр
Яктылык, матурлык.
Күңелләр гел аңа
Торадыр тартылып.


Җәен дә истә ул
Йөрсәң дә кайда да.
Сентябрь җиттеме,
Чакырып кайтара.

Бакчасы бик матур,
Ямь генә тирә-юнь.
Тик һаман класска
Ашкына йөрәгең.

Шушында ачыла
Дөньяның бар сере,
Яктыра бу җирнең
Туачак гасыры.

Иң нурлы изге йорт —
Кадерле кемгә дә.
Иң саф уй күңелдә
Бу йортка килгәндә,
Класска кергәндә.





Укырга һәм язарга өйрәнәм


Бу — мәк-тәп.
Әл-фи-я а-па — без-нең у-кы-ту-чы-быз.
Мин ки-тап у-кыйм.
Фә-рит рә-сем я-сый.
Лә-лә я-за.
Рә-ис ши-гырь сөй-ли.


ӘЙДӘ, ДУСКАЙ, СИН ДӘ ТҮБӘНДӘГЕ СҮЗЛӘРНЕ МАТУР ИТЕП ЯЗЫП КАРА:


Алма
Китап
Әлифба
Чәчәк
Без укыйбыз



Рәсемнәргә игътибар белән кара һәм алар арасындагы аерманы тап








Гөмбәле рәсемгә карап, икенчесен тиешле буяулар (карандашлар) ярдәмендә буяп бетер







Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Таныш булыгыз: Безнең дуслар – сезнең дуслар









Бу – Шүркә. Ул әтисе Шүрәле белән урманда яши. Җәнлекләр, кошлар, үсемлекләр тормышы белән бик кызыксына.



Елмай. Күргәнеңчә, бик чибәр, һәрвакыт елмая. Матур, дөрес җөмләләр төзеп сөйләшүче балаларны ярата. Кул эшләре белән шөгыльләнә.



Нәрсәкәй. «Бишле»гә генә укый. Гел дәресен хәзерли, язуы да пөхтә. Татарча китаплар укырга бик ярата. Дуслары, сораулары булса, Нәрсәкәйгә киңәш сорарга бара.



Шүрбикә. Шүркәнең әбисе. Шүркәгә тәмле ашлар, пәрәмәчләр пешереп ашата. Онытына һәм аның дусларына әкиятләр, мөнәҗәтләр сөйли.



Шалай. Шүркә белән быел беренче сыйныфка бардылар (сыйныфташлар). Уйнарга, такмаклар сөйләргә, башваткычлар чишәргә ярата.



Балалар трамвайда мәктәпкә бара. Аларның өчесенә 3 әби урын бирә. 2 бала әбиләргә рәхмәт әйтә. Берсе дәшми. Син бу балаларның кайсыларына охшарга теләр идең?

Айрат көн дә мәктәпкә йөри. Һәм ул һәр көнне бер «бишле» эләктерә. 2 атна эчендә Айрат ничә «бишле» ала?



Марат белән Русланның мәктәпкә укырга барасылары килми. Шуңа күрә аларны өлкәннәр озата бара. Атнаның 3 көнендә малайларны әбиләре илтә. Ә калган көннәрдә бабалары. Бабалары ничә көн озата?

Айнур дәрес вакытында укытучы сөйләгәнне тыңламыйча, туңдырма турында уйлап утыра. Ул дәрес вакытында үз хыялында 2 туңдырма ашап бетерә. Бер көнне — 4, икенче көнне 5 дәрес булса, Айнур хыялында 2 көн эчендә ничә туңдырма сыптырып куячак?

Балалар бакчасына йөрүче Алсуның 3 курчагы бар. Аларның икесе кара чәчле. Ә бүген Алсуның сары чәчле курчагы, бакчага барасым килми, дип карышты. Кара чәчлеләре шатланып барды. Алсуның ничә курчагы өйдә утырып калды?



Әйдәгез, уйныйбыз

Санамыш

Әлчи-бәлчи,
Әни күлмәк үлчи,
Чәүкә, чыпчык!
Син кал — мин чык!
Ары алачык, бире алачык,
Кыр капкасы шыр ачык;
Анда чыпчык, монда чыпчык,
Син дә торма, йөгереп чык!



Җепсез орчык,
Чәүкә, чыпчык,
Кар, балчык,
Син кал, бу — чык!



Бармак уеннары

Олыга утын ярырга,
Ә сиңа — су китерергә,
Уртага мичкә ягарга,
Ә сиңа — казан асарга,
Чәнчигә — җырлый башларга.
Дусларның күңелен ачарга.

Бу бармак — бабай,
Бу бармак — әби,
Бу бармак — әти,
Бу бармак — әни,
Бу бармак — нәни бәби,
Аның исеме Чәнти!

— Бармак, бармак,
Кайда булдың?
— Бу абый белән
Урманга бардым.
Бу абый белән
Кырда йөрдем.
Бу абый белән
Ботка ашадым.
Бу энем белән
Җыр җырладым.

Бусы ашаган,
Бусы ашаган,
Бусы ашаган,
Бусы кечкенә булганга,
Кетер-кетер казан кимергән.



Гөлбаһар

Балалар кулга кул тотынышып бер сафка басалар. Алдарак басып торган бакча каравылчысы «Гөлбаһар әби» була. Каршы яктан бер бала көтүче булып килә. Җырлый:

— Әй, әбекәем, Гөлбаһар,
Синең артта ниләр бар?
— Шалкан белән торма бар.
— Берсен миңа бирсәнә!
— Көчең җитсә тартып ал!



Көтүче балаларның берсен тотып үз ягына тарта, суыра башлый, ә «әби» аның юлына каршы торып, йолкытмаска тырыша.

«Шалкан-тормалар» бар да бер-берсенә нык тотышкан, ычкынмаска, иптәшен дә ычкындырмаска тырыша. Шулай берәм-берәм суырып алып бетергәнче уен бара.



Җиде кыз

(В. Сухомлинский әкияте буенча)

Бер ананың җиде кызы булган. Бервакыт ул бик еракта яшәүче улы янына барган да, аннан бер атнадан соң гына кире кайткан. Әниләрен күрүгә, кыз-



лары берсен-берсе уздыра-уздыра, аны ничек сагынганнары хакында сөйләргә тотынганнар.

— Мин сине мәк чәчәге кояшлы аланын сагынган кебек сагындым, — дигән беренче кызы.

— Мин сине коры җир су тамчысын көткәндәй көттем, — дип әйткән икенчесе.

— Ә мин кош баласы әнкәсен сагынып елаган шикелле еладым, — дип өзгәләнгән өченче кыз.

— Минем өчен синсез калу бал корты чәчәксез калуга тиңдер, — дигән дүртенчесе.

— Гөлчәчәк төшендә чык тамчысын күргән сыман, мин сине гел төшләремдә күрдем, — дигән бишенче кыз.

— Мин сине, чия бакчасы сандугачны күзләгәндәй, тәрәзәдән күзләремне алмыйча көттем, — дигән алтынчысы.

Җиденче кыз исә бер сүз дә дәшмәгән. Ул әнисенең башмакларын салдырган да, аңа аякларын юу өчен җылы су китергән.



ҖИДЕНЧЕ КЫЗ БАШКАЛАРДАН КАЙСЫ ЯГЫ БЕЛӘН АЕРЫЛЫП ТОРА?

НИЧЕК УЙЛЫЙСЫҢ, КАЙСЫ КЫЕНРАК: МАТУР СҮЗЛӘР СӨЙЛӘҮМЕ, ӘЛЛӘ МАТУР ЭШ ЭШЛӘҮМЕ?

ӘНИЕҢ АРЫГАН ЧАКТА СИН АНЫҢ ӨЧЕН НИЛӘР ЭШЛИСЕҢ?

СИН ӘНИЕҢНЕ НИНДИ ЧӘЧӘККӘ ОХШАТАСЫҢ?

ӘНИЕҢНЕ НИ-НӘРСӘ КҮБРӘК СӨЕНДЕРӘ? НӘРСӘДӘН АНЫҢ КӘЕФЕ БИК ТИЗ ТӨШӘ?

ӘНИЕҢНЕҢ ТУГАН КӨНЕНӘ СИН НӘРСӘ БҮЛӘК ИТӘСЕҢ?

ЙӘЛЕ, ДУСКАЙ, ӘНИЕҢНЕҢ РӘСЕМЕН ЯСАП КАРА.



Рәссам Диләрә НӘУРУЗОВА



ДУСКАЙ, БҮРЕЛӘР ТУРЫНДА СИН НИЛӘР БЕЛӘСЕҢ?




БҮРЕ РӘСЕМЕН ҮЗЕҢ ЯСАП КАРА.



СОРЫ БҮРЕ

Көз. Кичке эңгер-меңгер соры җәймә булып урман өстенә ябылган. Басу-кырларга ук терәлгән урман авызы турысыннан ялгыз бүренең сузып-сузып улаганы-җырлаганы ишетелә: «Уууу-у-у... ууу...» Аның бу җырында төнге суыктан калтырану, ялгызлыктан интегү, табыш эзләү газабы һәм кешедән курку хисе бар сыман. Кызык, бер ашаганда бүре күпме ашый ала икән? Бик ач булган очракта — ун килограмм чамасы ит кирәк аңа. Гадәттә бүрегә ике килограммга якын азык җитә, калган табышын ул яңадан ашарга дип яшереп куя. Бүре бик көчле, җитез, беркайчан да талчыкмый.

Бер сарыкны тешләгән килеш ул шактый ара үтә ала. Зур хайванга, әйтик, пошига бүреләр өерләре белән ташлана: берәүләре корбанны арттан эзәрлекли, ә икенчеләре кырыйлап каршыга төшә.



СКАНВОРД

Төзеде Гүзәл СИРАҖЕВА





ЯССЫ РӘСЕМ ЯСАРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

Кадерле дускай, синең рәсем ясарга ратканыңны белеп торабыз. Матур рәсемнәр белән синнән бик күп хатлар килә, рәхмәт! Ләкин рәсем ясауның үзенә генә хас кагыйдә-ысуллары бар. Әйдә, бүген бергәләп алар белән танышып карыйк. Йә, башладык!

Биш очлы йолдыз биш тигез дүртпочмактан тора. Алар үзәктән бертигез арада урнашкан. Бу форма җайлы гына түгәрәк рәвеше эченә керә. Әйдә, башта түгәрәк ясыйк (циркуль кулланcаң да була). Һәрьяктан очлар билгелибез. Килеп чыккан дүрт өлешне улчәп, түгәрәктә биш нокта куярга кирәк. Аннары аларны йолдыз формасы килеп чыксын өчен линейка ярдәмендә бер-берсе белән кушабыз. Өстәге ноктаны астагылары белән, ә аларны кырыйдагы нокталар белән беркетәбез.



Кирәк булмаган сызыкларны бетергеч белән сөртик.

Күрәсеңме, нинди тигез йолдыз барлыкка килде?! Шуны куе кызыл буяу белән пөхтә итеп буяп куй! Булдырдың!



ЦИРКУЛЬ — түгәрәк форма ясау өчен рәсем әсбабы

БЕТЕРГЕЧ — стёрка, ластик

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

РӘСЕМ



Әни биргән бер карандаш,
бер бит кәгазь алда.
Нәрсә төшерим аңа?

Ник аптырап торырга,
баш кашып утырырга?
Нәрсә ясыйсым беләм —
кәгаземә кош төшерәм!

Тәвәккәлләп тотынгач,
булсын булгач —
сандугач!

Йомры башын төшердем,
томшыгын килештердем,
канатларын җәюле —
оча торган иттердем.
Кул белгәч, рәхәт кенә!
Тиз генә, җәһәт кенә
карандашымны йөртәм,
тәпиләрен җәпле иттем,
түшләренә миң тёрттем —
рәсемемне өлгерттем!

Карадым барып читтән,
рәсемем ничек икән?
Уңга да чыгып карыйм,
сулга да чыгып карыйм,
карый-карый аптырыйм —
ошамый бит күңелгә.
Бу — сандугач түгел лә!
Әнигә әйтәм: булыш, дим,
әйтче, бу нинди кош? — дим.

«Бигрәк олы икән, — ди, —
карга түгел микән?» — ди.
Үзен бер дә күрмәгәч,
артыннан йөгермәгәч,
юньле-башлы белмәгәч,
китаптан укып кына,
җырлардан отып кына,
сурәтен тотып кына,
тиз генә, ансат кына
булмады ясап кына
кошларның мактаулысын.
Нишлим соң шулай булгач:
Сау бул инде, сандугач!

Яңа рәсем ясасам,
күргәнне ясаячакмын,
белгәнне ясаячакмын:
карлыгачны, чыпчыкны,
үзем ясаган ояда
кагынган сыерчыкны.
Йә булмаса, әбиемнең
кулындагы орчыкны...
Ясар идем әллә ниләр,
әни биргән ак кәгаземә,
карандашым бер генә...

Гомерем шул бер генә..







Сентябрь житкәч

Озаттым абыемны,
Апамны илтеп куйдым.
Ә үзем өйдә калам:
Алты яшь яңа тулды.

Түзәм инде, көтәм инде —
Тагын сентябрь җитәр.
Нәкъ бер елдан
Ходай кушып,
Мин дә мәктәпкә китәм.

Ә хәзергә, әлегә
Ачтым мәктәп өемдә.
Укыйм туган телемдә!
Сөйлим әнкәм телендә!
Әткәм-әнкәмнең телен
Кирәк бик тә белергә!

Үзем директор булдым
Һәм үзем укытучы!
Уенчыклар һәммәсе дә —
Бик тәртипле укучы!

Нидән башлыйк дәресне дип,
Без аптырап тормадык.
Ясандык та матур итеп,
«Туган тел»не җырладык!..

Песи гармун уйнады,
Кәҗә дирижер бездә.
Өебездә һәммәсе дә
Сөйләшә туган телдә.

Бар телләр дә бертигез —
Юк кечесе, олысы!
Тоясыңмы, туган телдә —
Әниеңнең җылысы?!

Әйе, туган телемдә —
Елмаюы әткәмнең.
Әйбәт аңлый көчегем дә
Татарча сөйләшкәнне.

Минем туган телемдә
Бабамның хикмәтләре.
Әбиемнең сөйләгән
Кичке әкиятләре.

Энемнең көлүләре,
Күршенең кеткелдәве.
Карчыкларның моңлы итеп
Мөнәҗәтләр көйләве.

Мәктәпнең исемен дә —
«Төрки йорт» дип атадык!..
Без, нәниләр, нәкъ татарча —
Зур тормышка атладык!..

Укучым! Хәйрүшнең яңа мажаралары турында киләсе саннардан укырсың.



Зиннур ХӨСНИЯР



Синең дусларың алдында чыгыш ясаганың булгандыр. Игътибар яулау, әйтергә теләгәнеңне җиткерү өчен, әлбәттә, синең сөйләмең матур, төзек, дөрес булырга тиеш. «Салават күпере» журналы сиңа, дускай, киңәшләрен бирергә тели.

Чыгышыңны нинди максат белән (нәрсәгә), нәрсә турында, нинди сүзләр ярдәмендә төзүеңне алдан уйлап куй.

Төп фикерең нинди?



ЧҮЛ САКЧЫСЫ

Чүл — җәнлекләр һәм кошлар яши торган бик зур дала. Андый кошжәнлекләр дөньяда бик сирәк, аларны бары тик чүлдә күрергә мөмкин...

Җәйнең бер матур көнендә чүлгә җәнлекләрне үтерергә, юк итәргә, дип бик усал кеше килә. Җәнлекләр бу усал кеше турында ишеткәч куркуга калалар. Киңәш сорарга дип, болар җыелышып, уттай кызыл Кәлтәгә барырга булалар.

— Арабызда син иң акыллысы, зинһар, киңәш бир. Чүлгә килгән усал кешедән безгә ничек сакланырга икән?

Кәлтә әйтә:

— Тынычланыгыз. Миңа уйларга вакыт бирегез.

Бераздан ул:

— Мин уйладым. Әгәр дә усал кеше килүе турында берәрсе алдан хәбәр бирсә, сез вакытында качып, аннан котыла алырсыз. Сезгә сакчы кирәк! — диде.



ЧҮЛ — пустыня
КӘЛТӘ — ящерица



ЧҮЛ ҖӘНЛЕКЛӘРЕ НИ ӨЧЕН КӘЛТӘГӘ КИЛӘЛӘР?
НИ ӨЧЕН КӘЛТӘ СОРАУГА ТИЗ АРАДА ҖАВАП БИРМӘДЕ?
КӘЛТӘ НИНДИ КИҢӘШ БИРӘ?
ЧҮЛДӘ НИНДИ ҖӘНЛЕКЛӘР, КОШЛАР ЯШИ ИКӘН?
РӘСЕМГӘ КАРАП ХИКӘЯ ЯЗ ҺӘМ БЕРӘР КЕШЕ АЛДЫНДА ЧЫГЫШ ЯСА!
УҢЫШЛАР!





Кишер гаиләсе

(Кишер алганда туган әкият)

Борын заманда түгел, хәзерге заманда бер капчыкта орлыклар яшәгән. Алар үзара бик тату бер гаилә булып көн күргәннәр. Кыш үткәч, яз җиткән. Бакчачы килгән дә, бу орлыкларны күзләрне камаштырырлык яктыга чыгарган һәм мамык кебек кабарып торган җылы туфракка сипкән. Орлыклар караңгыга эләккәч, бик куркуга калганнар, бер-берләрен югалтканнар. Тизрәк туганнарын эзләп табарга теләп, кулларын югарыга сузганнар. Шулай итеп, бу орлыклар гаиләсе чәчелгән түтәл өсте яшел сабак-куллар белән тулган. Сабаклар бер-берләренә тотынышып һаман үскәннәр, көчәйгәннәр. Яңгыр аларга көч, ә кояш дәрт биреп торган. Бакчачы килеп төпләрен йомшарткан, чүп үләннәреннән арындырган.

Көз җиткән. Көннәр кыскарган, кояш та нурларын саран чәчә башлаган. Бакчачы җиргә күмгән теге орлыкларны казый башлаган. Ә алар... кояш төсен үзләренә сеңдергән кишерләр булып үскәннәр! Җир өстенә чыгып бер-берләрен күргәч, алар шаккатканнар. Менә нәрсә эшләткән аларны йомшак туфрак, җылы яңгыр һәм кояш!



Энҗе ГАФАРОВА, 9 яшь.
Апас, Каратун
(әкияте дә аныкы).




БЕЗ «ТЕРЕМОК» БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА КУНАКТА! «ТЕРЕМОК» — ТАТАРСТАНЫБЫЗНЫҢ БУА ШӘҺӘРЕНДӘ УРНАШКАН. ҺӘР КӨН БАКЧАГА 100 ДӘН АРТЫК БАЛА КИЛӘ. АЛАРГА 12 ТӘРБИЯЧЕ, 17 ТЕХНИК ПЕРСОНАЛ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТӘ. БАЛАЛАР 4 ТӨРКЕМГӘ БҮЛЕНЕП УЙНЫЙЛАР, АШЫЙЛАР, ЙОКЛЫЙЛАР, ЯГЪНИ РӘХӘТЛӘНЕП КҮҢЕЛ АЧАЛАР.

БЫЕЛ «ТЕРЕМОК»КА 25 ЯШЬ ТУЛА. КОТ-ЛЫЙ-БЫЗ!











ХӨРМӘТЛЕ ТӘРБИЯЧЕЛӘР, ӘТИ-ӘНИЛӘР! «Салават күпере»нең алдагы саннарында балалар бакчаларында тәрбияләнүче нарасыйларыгызның фотосурәтләрен күрәсегез килсә, тиз арада журналханә белән элемтәгә керегез (телефон номерлары журналның алгы өлешендә күрсәтелгән). Бу уңайдан бер шартыбыз бар: фотосурәтләрне безгә юллаганда хат белән бергә журналга язылу хакындагы квитанцияләрнең күчермәләрен җибәрү мөһим.



Сәлим спорт белән шөгыльләнергә ярата. Дуслары белән җыелышып, алар еш кына футбол, теннис яисә волейбол уйныйлар. Узган җәй көннәрендә рәхәтләнеп су коендылар. Спортны ярataлар, ә Универсиаданың нәрсә икәнен беләләр микән? Йәгез, үзләреннән сорап карыйк әле.

Сәлим: «Әйе, беләм, Универсиада ул — бөтендөнья студентлары арасында уза торган спорт ярышы. Беренче тапкыр ул 1923 елның маенда Париж шәһәрендә (Франция) уздырылган. 1959 елдан бу студентлар спорт ярышы «Универсиада» исемен йөртә башлый (Турин шәһәре, Италия). Универсиада программасында спортның 13 төре бар: җиңел атлетика, футбол, баскетбол, спорт гимнастикасы, нәфис гимнастика, фехтование, йөзү, су полосы, теннис, өстәл теннисы, волейбол, суга сикерү, дзюдо. Өстәмә 3 спорт төрен Универсиаданы уздыручы шәһәр үзе сайлый ала».

Ура-ура! 2013 елда Универсиада мәркәзебез Казанда уздырылачак! Нинди шатлык. Әйдәгез, бергәләп ярышларга әзерләнә башлыйк.

UNIVERSIADE
KAZAN
2013
RUSSIA

УНИВЕРСИАДА НӘРСӘ УЛ?

УЛ КАЗАНДА КАЙЧАН БУЛАЧАК?

СИН СПОРТНЫҢ НИНДИ ТӨРЛӘРЕ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘСЕҢ?





Сыбызгы

Спорт белән кызыксыну
Увлекаться спортом
Do in for sports [`dəuin fə`spo:ts]



Сәлим спорт белән шөгыльләнә
Салим увлекается спортом
Salim do in for sports

Футбол
Футбол
Football [`futbo:l]




Дуслар мәктәптән соң еш кына футбол уйныйлар
После школы друзья часто играют в футбол
Friends often plays football after school

Футболчы
Футболист
Footballer [`futbo:lə]



Ул әйбәт футболчы
Он хороший футболист
He is a good footballer

«Әйдә футбол уйныйбыз!» — ди Сәлим
«Давай поиграем в футбол!» — говорит Салим
«Let`s play football», — says Salim





Рөстәм МИНГАЛИМ

Чыпчык-чырылдык – минем иң яраткан кошым



Башсыз тукран да түгел, мактанчык сыерчык та түгел, көяз саескан да түгел, шапшак күгәрчен дә түгел, минем иң яраткан кошым — чыпчык-чырылдык.

Ни өчен шулаймы? Хәзер-хәзер сөйлим. Без — сугыш чоры балалары. Ул чакларда җәйләр бүтән, кышлар башка иде. Үзебез ач, киемнәр ертык, кышлар коточкыч салкын. Шундый салкын кышкы бер көндә урамда йөрим. Баш өстемнән бертөркем чыпчык пырлап очып узды. Кинәт араларыннан берсе карга егылып калды. Мин аны кулыма алдым. Ул шундый йомшак, аяклары бигрәк нечкә, кечкенә соры борыны искиткеч матур. Мин аны ике тапкыр үптем. Башы кызганыч кечкенә. Бу чыпчык туңып төшкән, безнең балачактагы салкын кышларда кошларның туңып төшүе — гадәти күренеш иде. Мин бу чыркылдыкны тыным белән җылытып терелтергә тырыштым, булмады. Ул учымда үлде. Мескен, чыпчык, җылы якларга очкан булса бит инде, анда болай үлеп егылмас иде. Безнең өй кыегындагы оясында яшәгән чыпчык булды бугай ул. Аны күмәргә ачык җир дә юк бит әле, тирә-юнь ап-ак — тирән кар гына. Авыл каберлегенә барып көчкә-көчкә карга гына күмәргә туры килде. Аны күмүе бик кызганыч булса да, кечкенә йомшак башы, сөм-соры борыны гел күз алдымда. Ул бит безнең өйне ташлап җылы якка да китәргә теләмәгән. Әллә башы бәләкәй булганга безнең якка бик салкын кыш килерен уйлый белмәде микән? Чыпчыклар шулай шул, китмиләр. Әнә шул мин сөйләгән салкын кыштан бирле чыпчык-чырылдыклар минем иң яраткан кошларыма әйләнделәр бугай.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

ДУСКАЙ, СИН НИНДИ КОШНЫ АЕРУЧА ЯРАТАСЫҢ?
КОШЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ВАКЫЙГАЛАРНЫ ИСЕҢӘ ТӨШЕР ДӘ ЯШЬТӘШЛӘРЕҢӘ, ДУСЛАРЫҢА СӨЙЛӘ.



Таныш булмаган кешеләргә ишек ачма!



Өлкәннәр кыңгырау тавышын ишеткәч, ишекне ачканчы анда кем барлыгы белән кызыксыналар. Моның өчен ишектә махсус җайланма — «күзлек» һәм чылбыр була.


Кечкенә дускай, син дә чит кешеләргә ишек ачканда сак бул.

КИҢӘШ-КАГЫЙДӘЛӘР:

- Таныш булмаган кешеләргә ишек ачма, алар белән сөйләшмә.
- Ят кешеләр, әтиең яки әниең ишекне ачарга кушты, дисәләр дә — ышанма. Әти-әниең сиңа бу хакта телефоннан шалтыратып әйтергә тиеш иде.
- Ишеккә килгән кеше йозакны үзе ача башласа, бик тиз генә әти-әниеңә яки милициягә шалтырат. Адресыңны хәбәр ит.
- Әгәр өйдә телефон юк икән, тәрәзә яки балкон аша урамнан узып баручыларны ярдәмгә чакыр.
- Милиция яки табиб киеменнән килүчеләргә дә уйламый ишек ачарга ярамый. Сиңа ишек ачтырганчы алар күршедәге өлкәннәргә мөрәҗәгать итсеннәр.
- Өйдә үзең генә булмасаң да, өлкәннәр рөхсәтеннән башка ишек ачарга ашыкма.

Әлеге кагыйдәләрне онытма!






СИН ӨЙДӘ ЕШ ЯЛГЫЗ КАЛАСЫҢМЫ?
ҮЗЕҢ ГЕНӘ БУЛГАНДА ИШЕКНЕ ШАКУЧЫЛАР БАРМЫ?
ИШЕК АРТЫНДА КЕМ ИКӘНЛЕГЕН НИЧЕК БЕЛЕП БУЛА?
ШАЛТЫРАТУЧЫ КЕШЕ АК ХАЛАТТАН БУЛСА ҺӘМ ҮЗЕН ТАБИБ ДИП ТАНЫШТЫРСА, СИН НИШЛИСЕҢ?

ТЕЛЕФОН НОМЕРЛАРЫН ЯЗЫП, ИҢ КҮРЕНӘ ТОРГАН УРЫНГА ЭЛЕП КУЙ!

ӘТИ —
ӘНИ —
ДӘҮ ӘТИ —
ДӘҮ ӘНИ —
ДУСТЫМ —
ЯНГЫН
СҮНДЕРҮЧЕЛӘР — 01
МИЛИЦИЯ — 02
АШЫГЫЧ ЯРДӘМ — 03
МИНЕМ АДРЕС —
МИНЕМ ТЕЛЕФОН —







Бабай



Айдар бабасы белән бик дус. Малайның әти-әнисе көндез эштә чакта бабай йорт эшләрен карый, оныгына ярдәм күрсәтә, киңәшләрен бирә. Хәтта мәктәптә биргән өй эшләрен дә Айдар өчен бабасы эшли икән.

— Бабай, бу мисалны чишеп бир әле. Бүген малайлар белән футбол уйнарга тиешбез — өлгермәм, — ди Айдар.

— Әйдә, башта мәсьәләләрне чишик, аннары футболга бергә барырбыз, — дип әйтеп карый бабасы.

— Юк, бабай, син өйдә генә утыр, салкын тидерерсең, — дип Айдар сүзне бүтән якка борып җибәрә.

Бабай өйдә тыныч кына өй эшен эшләп кала. Кичке аштан соң оныгына мәсьәләләрнең чишелешен аңлатырга тотына. Футболдан арып кайткан Айдар, аны тыңлар-тыңламас утыра. Берничә елдан зуррак проблемалар башланып китә.

— Айдар, улым, мин бу мисалларны чишә алмыйм шул. Ниндидер X һәм У лар, билгеле булмаган саннар күп, — ди бабасы.

Шул көннән Айдар өй эшләрен бабасы ярдәменнән башка әзерли башлый. «Икеле» куелган дәфтәрләрен ташлап барып, контроль эшләрне дустыннан күчерә.

Бер тапкыр укытучы апа каядыр бик ашыгу сәбәпле, Айдарга сыйныф журналын укытучылар бүлмәсенә илтеп куярга куша. Шулчак Айдар озак уйлап тормыйча, журналга бер-ике «бишле» тертеп куя. Икенче көнне йөрәге дөп-дөп итеп тибә. Ни бәхет, укытучы берни сизми кала. Шундый фокус-мокуслар ешая башлый.

Бер көн укытучы апа балаларга дәфтәрләрен таратып, соңгы мөстәкыйль эш билгеләрен әйтүләрен сорый. Чират Айдарга җиткәч, ул ялтырап торган «икеле» урынына оялмыйча «өчле» дип әйтә. Укытучы аптырашта калып:

— Йәле, дәфтәреңне алып килеп күрсәтче, — дию булa, партадаш малай Нияз кылана башлый. Йә әтәч булып кычкыра, йә бәрән булып «бәэлдәп» карый. Ниязны тәртибе өчен класстан



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

куып чыгаралар. Укытучы Айдар турында оныта. Шулай алдалый - ялганлый Айдар математикадан билгеләр алып бара.

Уку елы азагы иде. Бер көн әнисе эштән кайткач, кырыс тавыш белән Айдарны чакырып ала:

— Бүген укытучың шалтыратты, бер дә белемнәрең юк дип әйтә. Бу хәлне аңлатып бир әле, улым...

— Минем соңгы вакытта башым авырта, — дип акланырга тырыша Айдар.

Малай бүлмәсенә кереп киттә дә диванга ятып күзләрен йома. Шулвакыт аның янына бабасы керә. Нәрсә булганын аңлап, ул әкрен генә сөйли башлый: «Без сугыш вакытында үстек. Әти фронтка киткәч, әни заводта эшләде. Миңа — сигез, энем Алмазга өч яшь иде. Көндезләрен энекәшне мин карыйм, уйната идем. Һәркөн әни безгә бер тәлинкә аш яки ботка калдырып, тигез итеп бүлешеп ашарга куша иде. Мин тәлинкәне уртабызга куеп, үзем зур кашык алып, энем Алмазга кечкенәсен бирәм. Алмаз калагы белән бер-ике капканчы, мин тәлинкәне ялтыратып куям. Ләкин тамак туймый, безнең гел ашыйсы килә иде.

Бер мәл Алмаз авырый башлады. Табиб абый энемне килеп карагач, аңа тиз арада берәр туклыклы әйбер ашатырга кушты. Әни ризык әзерләргә чыгып йөгерде. Кичкә ул каяндыр сөт, күкәй, май алып кайтты.

Мин әнигә дөресен сөйләргә булдым.

Шулчак әни миңа:

— Бу сиңа сабак булыр. Кечкенә ялган — зурны, ә зурысы төзәтеп булмас начар хәлләр тудыра, — диде.

Айдар җәй буе укып, мисаллар чиште. Көзгә математикадан билгесе «дүртле» булды.



СУГЫШ, АЧЛЫК ВАКЫТЫНДАГЫ ЯЛГАННЫ АҢЛАП, АКЛАП БУЛАМЫ?

НИ ӨЧЕН БАБАЙ ЭНЕСЕ БЕЛӘН БУЛГАН ВАКЫЙГАНЫ АЙДАРГА СӨЙЛӘДЕ?

СИНЕҢ АЙДАР ХӘЛЕНДӘ КАЛГАНЫҢ БАРМЫ?

Материалны «Гармония» психологлары әзерләде.
Адресы: Казан, Г. Исхакый ур.,8.
Тел.: 292-18-39, 292-07-98.



Мин бит бу!

Кому

Куда г.Казань, ул.Муштари, 14.

Индекс места отправителя

Индекс места назначения

420012



Айсылу, 7 яшь
Таңсылу, 6 яшь

— Без икебез шушы өйнең
Бәхетле сылулары:
Соклandырсын Ай һәм Таңның
Янәшә булулары!

Биектау, Калинино.



Ралинә, 2 яшь 2 ай

— Уенчыкларыма кирәк
Дәү кызлар тәрбиясе:
Кем белә, бәлки, үскәчтен
Булырмын тәрбияче!

Әлмәт, Яңа Кәшер.



Алия, 2 яшь 8 ай
Ренал, 1 яшь 7 ай
Мансур, 7 яшь
Самат, 2 яшь 7 ай

— Йөрдек инде куышып та,
Ардык инде уйнап та...
Әллә барып кайтабызмы
Табигатькә кунакка?!

Актаныш, Такталачык.



Инзил, 1 яшь 8 ай

— Әкиятләр сөйләтәм,
Матур көйләр көйләтәм...
Бүген бездә — җыр дәресе:
Җыр җырларга өйрәтәм!

Апас, Каратун.



Эмилия, 7 яшь

— Кәгазь, каләм һәм конверт
Кулыма алыйм әле.
«Салават күпере»нә
Хат язып салыйм әле!

Азнакай.



ЯҢА ХАТЛАР КӨТӘБЕЗ!



Алтын куллар

Җәйге болын

«Болынның хуҗасы» Казанның 414 нче балалар бакчасына йөрүче Алёна исемле кыз.



Чәчкәләрне без төрле төстәге (кызыл, сары, алсу, зәңгәрсу) гофрир кәгазьдән эшлибез. Кәгазьләрне кечкенә түгәрәк формасында кисеп, җилем белән берберсенә беркетәбез. Кырыйларын матурлыйбыз, аннары яшел «болынга» каптырып куярга кирәк. Соңыннан чәчәкләр янына киптерелгән яфракүләннәрне пөхтә итеп ябыштырабыз. Бик гади булса да, эшебез искиткеч матур булып чыкты!

Фантазияңне куллан: эшне бисер, төймә, тасмалар белән матурласаң да була.





Канатлы талант

Җәмилә ҖИҺАНШИНА:

«Сәлам! Миңа 12 яшь, Казанда яшим. Скрипка, фортепиано, курайда уйнарга өйрәнәм. Матурлык бәйгеләрендә катнашканда бөтен дөньяга биеп тә күрсәтә алдым. Буш вакытымда хип-хоп, классик музыка тыңлыйм, «Салават күпере»н бик яратып укыйм! Минемчә, максатчан кеше барлык теләкләренә дә ирешә. Хыялым — балерина булу».







Җәмилә ҖИҺАНШИНА җиңүләре:
«Мини-мисс Татарстан-2008»,
«Мисс мира-2008» бәйгесендә
«Иң яхшы биюче»,
«Мини-мисс Планета-2009».